**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4274**
**19.08.2019**

Муниципаль ихтыяҗлар өчен
җир участогын кире алу турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыруның тимер юлы транспорты объектларын (трамвай юлларын) төзү өлешендә расланган проектында каралган җирле әһәмияткә ия объектларны төзү максатында, РФ Җир кодексының 11, 49, 56.2, 56.3, 56.6, 56.7, 56.8, 56.10 маддәләре, Башкарма комитетның «Тимер юлы транспорты объектларын (трамвай юлларын) төзү өлешендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проектын раслау турында» 2015 елның 14 сентябрендәге 5207 нче карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен кире алырга:
Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспектының «Райисполком» тукталышы районында 17 микрорайон ягында урнашкан, Дряблов Владимир Аркадьевичның милекчелек хокукындагы мәйданы 176 кв.м булган җир участогын (кадастр номеры 16:52:050306:129), рөхсәт ителгән файдалану төре - «сәүдә-күңел ачу үзәге».

2. Муниципаль ихтыяҗлар өчен кире алырга:
Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән кире алынган җир участогында урнашкан сәүдә залы күчемсез мөлкәтен (кадастр номеры 16:52:050306:151), аның чикләрендә урнашкан түбәндәге биналар белән:

1) Дряблов Владимир Аркадьевичның милекчелек хокукындагы торак булмаган бина (кадастр номеры 16:52:050306:219);

2) «Город+» ҖЧҖ милекчелек хокукындагы торак булмаган бина (кадастр номеры 16:52:050306:7944).

3. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, закон тәртибендә билгеләнгәнчә, карарның күчермәләрен әлеге карарның 1, 2

пунктларында күрсәтелгән, кире алынган күчемсез милек объектларына хокукы булган затка җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

4) кире алу нәтиҗәсендә туктатылган хокукларны һәм китерелгән зыянның күләмен бәяләү, шулай ук кире алынган күчемсез милеккә алмашка бирелә торган күчемсез милекне бәяләү өчен бәяләүче оешманы билгеләргә;

5) җир участогын кире алу буенча эш йомгаклары буенча җир участогын һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын муниципаль ихтыяҗлар өчен кире алу турында килешү әзерләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм җир мөнәсәбәтләре идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин